**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы,423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru


КАРАР

от «14» маеннан 2021 года № 222

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы педагогик хезмәткәрләренә – яшь белгечләргә айлык стимуллаштыручы өстәмә түләүләр билгеләү турында» 2019 елның 16 сентябрендәге 229 номерлы карары белән расланган, гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен башкаручы Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы спорт министрлыгы булган Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының муниципаль белем бирү оешмаларында эшләүче педагогик хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә ай саен стимуллаштыручы өстәмә түләү бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә яшьләр сәясәте турында» 2020 елның 30 декабрендәге 489-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республи касы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы педагогик хезмәткәрләренә – яшь белгечләргә айлык стимуллаштыручы өстәмә түләүләр билгеләү турында» 2019 елның 16 сентябрендәге 229 номерлы карары белән расланган, гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен башкаручы Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы спорт министрлыгы булган Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының муниципаль белем бирү оешмаларында эшләүче педагогик хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә ай саен стимуллаштыручы өстәмә түләү бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

3 пункттагы «30» цифрын «35» цифрына алмаштырырга.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://www.novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсъәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Фәсахов